КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 октябрь г.Казань № 920

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 432 нче карары белән расланган Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 962 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Сатулар үткәрмичә сатып алынулары гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктта:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциячел булмаган иптәшлегенә, гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләреннән тыш, мондый иптәшлек әгъзаларына бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен;»;

6 пунктчада «, дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән унбиш процентка тигез хак белән түбәндәгеләрне сату гамәлгә ашырыла:

1) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага, шәхси торак төзелеше максатларында, территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирелгән һәм уртак кулланылыштагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге коммерциячел булмаган оешмага;

2) юридик затка дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән һәм уртак кулланылыштагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге юридик затка. ».

2. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин